# КЕРЕШ

Балалар әдибе, балалар шагыйре, балалар язучысы… Бу исемгә лаек булу өчен, иҗатчыга табигый сәләт кенә түгел, күңел сафлыгы, риясыз самимилек, ихласлык, балалар зиһенe генә ирешә алырлык үткенлек тә кирәк. Шундый язучылар була: алар сәләтле дә, бөек тә, ләкин «балалар әдәбияты» дигән саф сулы елгага үз иҗат чишмәләренең мул суларын кушу, аны тагын да баету мөмкинлегеннән мәхрүмнәр. Чөнки балалар әдәбияты аеруча нечкә тоемлау, зәвык таләп итә. Ә бу сыйфатлар һәркемгә дә бирелми шул. Резеда Вәлиева — сабыйлар күңелен аңлап, аңлаешлы һәм гади, шаян һәм тапкыр итеп иҗат итә белә торган сирәк талантларның берсе.

Бу китап сезне Резеда Вәлиева дигән язучының бай һәм мул сулы иҗат дәрьясына алып керәчәк, кызыклы һәм мавыктыргыч хәлләр, гыйбрәтле вакыйгалар белән таныштырачак, йөрәктә шатлык кабыза, туган илгә мәхәббәт уята торган хисләр дөньясында йөртәчәк. Шулвакыт укучыларда «Кем икән соң ул Резеда Вәлиева?», «Ул кайда туып, кайсы чишмә суын эчеп үсте икән?» дигән сораулар туачак. Шуңа күрә без шагыйрәнең тормыш юлын яктыртып узуны кирәк таптык.

Резеда Тәфкәлүн кызы Вәлиева 1930 елның 1 маенда Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында укытучылар гаиләсендә туа. Аның әтисе — Башкортстанның һәм Россиянең атказанган укытучысы, ике тапкыр Ленин ордены иясе Тәфкәлүн Хәммәт улы Вәлиев — бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган хөрмәтле мөгаллим, мәктәп директоры. Ул балаларының күңелендә дә кечкенәдән әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләргә тырыша. Резеда апа да әдәбиятка килүенең төп этәргече дип нәкъ менә гаилә тәрбиясен атый. «Бу, иң беренче чиратта, матур әдәбиятсыз тора алмаган, шигъриятне яраткан гаиләдә үсүем белән бәйледер. Әткәм мәктәптә рус әдәбиятын укытты, татар әдәбиятын, аеруча Тукайны, Такташны үз итте. Әнкәм дә — укытучы. Халык мәкальләре, әйтемнәре аның авызыннан сибелеп кенә тора иде. Безнең өйдә һәрвакыт шигырь һәм җыр яңгырап

торды. Өстәвенә миннән кала өебездә бөтен кеше, әткәм белән әнкәм генә түгел, абыем белән апам да мандолинада уйный иде. Мин, укырга кергәнче үк, яттан шигырьләр сөйләргә, җырларга яраттым. Телем сакау булганга, үземнән рәхәтләнеп көләләр иде», — ди ул балачагы турында. Әлбәттә, мул сулы елгалары һәм күлләре, таш кыялары, серле тау куышлары, калын урманнары, киң кырлары булган гүзәл Урал табигате дә булачак шагыйрәнең күңелендә нечкә хисләр тәрбияләүгә үзенең өлешен керткәндер. Аның әтисенә, яңа мәктәпләр салдыра-салдыра, гаиләсе белән бик еш авылдан авылга күчеп йөрергә туры килә. Ә һәр яңа күченү ул — бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләр генә түгел, яңа танышлар, яңа мохит, яңа дөнья да. Шулай итеп, Резеда Вәлиева әле татар, әле башкорт, әле рус мәктәпләрендә укып, урта мәктәпне 1947 елда Салават районы үзәгендә тәмамлый. Ләкин тормыш дигәнең бары күңелле мәшәкатьләрдән генә тормый шул. Бу елларда илебезгә, шул исәптән Вәлиевләр гаиләсенә дә, Бөек Ватан сугышы фаҗигасе, газиз һәм кадерле кешеләреңне сугышка озату, аларны өзелеп көтү, ачлык-ялангачлык фаҗигасе килә. Бөек Ватан сугышы башланганда, унбер яшьтә генә булган автор сугыш афәтенең үз күңеленә ничек тәэсир итүен апасы Рәүзиягә багышлаган «Толымнарың синең» шигырендә бик ачык тасвирлый. Әдибәнең үз җаны аша узган бу фаҗига аның әсәрләрендә тетрәндергеч вакыйгалар, бигрәк тә чын образлар, персонажларның катлаулы эчке дөньясы, күңел газаплары рәвешендә урын ала. Резеда Вәлиеваның «Әбиемнең иске өен сүтteләр», «Кыз һәм каен», «Башыңны и аңа...», «Җиңү килгән көн» шигырьләрендә, «Канатлы җайдак», «Шагыйрь турында җыр» поэмаларында сугыш темасы төрле яклап ачыла.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Резеда Вәлиева Казанга килә. Казан... Тукай һәм Такташ Казаны... Яшь кызның хыялларында яшәгән Казан. Резеда Вәлиева Казан дәүләт университетының (хәзерге Казан (Идел буе) федераль университетының) татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, әдәби мохиттә кайный башлый. Аның сабакташлары — киләчәктә күренекле язучы яисә танылган әдәбият галиме булып киткән Гариф Ахунов, Мәхмүт Хөсәен, Фәрит Хатипов, Марат Сәгыйтов һ. б. 1952 елда, университетны тәмамлагач, Резеда Вәлиева Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли башлый. Аның беренче шигырьләре, беренче иҗат тәҗрибәләре дә шушы елларга туры килә. 1960 елда аның балалар өчен язылган «Минем дусларым» дигән китабы дөнья күрә. Шул елдан башлап дистәләгән шигырь һәм җыр җыентыклары, проза һәм тәрҗемә әсәрләре, язучы каләме аша үтеп, меңләгән укучыларны шатландыра.

Кызыклы, мавыктыргыч, шаянлыкка һәм тапкырлыкка корылган шигырьләр, әкиятләр, поэмалар, сәхнә әсәрләре Резеда апаның

каләменнән коелып кына тора. Ул әсәрләр туган илгә мәхәббәт тәрбияли, табигать белән дус булырга, хайваннарны һәм кош-кортларны рәнҗетмәскә, олыларны хөрмәт итәргә, тырышып укырга өйрәтә. Балаларга гына хас мәзәкчел ситуацияләрне, зирәклеккә, тапкырлыкка корылган вакыйга-хәлләрне, беркатлы сабый күңелендә генә туарга мөмкин булган каршылыкларны: уңайның — тискәрегә, тискәренең уңайга әйләнүен автор бик оста итеп, яратып сурәтли. Болар шагыйрәнең балалар психологиясен әйбәт белүе, аларның күңел дөньясын яхшы аңлавы хакында сөйли. «Мин гимназияләргә, мәктәпләр, китапханәләр һәм балалар бакчаларына еш йөрим. Әсәрләремне кычкырып укыганда, балаларның йөзләренә, күзләренә карыйм. Менә шунда күренә инде балага нәрсә ошый, нәрсә ошамый икәнлеге. Бала үзе турында, үз тормышы турында сөйләгәнне ярата. Үз тормышы нәрсә соң аның? Бу — мәктәп, андагы хәлләр, баланың гаиләсе, әти-әнисе, дәү әтисе, дәү әнисе, уй-хисләре, хыяллары...» — ди ул.

Резеда Вәлиеваның шигырьләре җырлап тора. Шуңа күрә үзеннән-үзе көй сорап торган бу әсәрләрнең җыр булып китүе табигый дә. Р. Вәлиева — дүрт йөздән артык җыр текстларының авторы.

Композиторлар аның шигырьләрен үзләре эзләп табалар, аларга көй язалар, һәм бу җырлар өлкәннәр тарафыннан да, балалар тарафыннан да яратып кабул ителә.

Балалар әдәбиятын әкиятләрдән башка күзаллап булмаган кебек, Резеда Вәлиева иҗатын да маҗаралы вакыйгалар, курку белмәс каһарманнар тормышы, серле, тылсымлы дөньяны сурәтли торган бу жанр әсәрләреннән башка күз алдына китерү кыен. Төрле елларда иҗат ителгән «Кышкы әкият», «Кәккүк», «Йолдызстан батыры» һ. б. әкияти поэмалары күптән инде балаларның яраткан әсәрләре исемлегендә. Аларда әдибә ялкаулыкны, көнчелекне, куркаклыкны хурлый, батырлыкка, тырышлыкка дан җырлый.

Бу китапта зур урынны патриотик рухлы поэмалар алып тора. Патриот шагыйрь Муса Җәлилнең батырлыгына багышланган «Шагыйрь турында җыр», ундүрт яшьлек каһарман Марат Казей турындагы «Канатлы җайдак» һ. б. поэмаларда шагыйрәнең туган иленә, халкына, аның батыр улларына мәхәббәте чагыла, күңел сафлыгына, намуслылык, рухи матурлык, батырлык һәм ватанпәрвәрлеккә мәдхия җырлана. Җиңел аңлаешлы, нәзакәтле, матур тел белән язылган бу әсәрләр бала күңелен туган телебезгә якынайталар, ата-анага, хезмәткә, туган илгә ихтирам хисе тәрбиялиләр.

*Әнвәр Хуҗиәхмәтов,*
педагогика фәннәре докторы, академик;

*Рәшит Фәтхерахманов,*
филология фәннәре кандидаты

## ВСТУПЛЕНИЕ

Детский писатель, детский поэт… Чтобы быть достойным этого имени, нужен не только литературный талант, дарованный Богом, но и чистота души, беззаботность, наивность и присущая лишь детскому разуму особая острота ума. Есть такие писатели: они и талантливы, и велики, но, к сожалению, лишены той исключительной возможности обогащения чистой реки под названием «детская литература» водами своих творческих источников. Да, детская литература требует особой проникновенности, тонкого чутья и, несомненно, высокого литературного вкуса. А эти качества, увы, даны не каждому. Резеда Валеева — одна из тех редких талантов, видящих насквозь внутренний мир детей и выражающих их чувства и переживания понятным и простым, в то же время удивительно красивым и остроумным языком.

Открыв эту книгу, вы войдёте в богатую и полноводную творческую реку поэтессы Резеды Валеевой, познакомитесь с интересными, увлекательными и поучительными историями, которые, мы уверены, воспитают в ваших сердцах любовь к Родине, родному народу, родителям. Тогда многие из вас непременно захотят узнать, кто же такая Резеда Валеева, где она родилась, в какой семье воспитывалась. Именно поэтому мы решили познакомить вас с биографией поэтессы.

Резеда Тавгалюновна Валеева родилась 1 мая 1930 года в деревне Душембеково Кигинского района Башкортостана в семье учителя. Её отец Тавгалюн Хамматович Валеев — заслуженный учитель Башкортостана и России, дважды награждённый орденом Ленина. Он был уважаемым педагогом, директором школы и посвятил всю свою жизнь воспитанию детей. Тавгалюн Хамматович старался привить и своим собственным детям любовь к литературе и искусству. И сама Резеда-апа первопричиной прихода в литературу называет атмосферу в семье и воспитание. «Это, в первую очередь, связано с тем, что я родилась в семье, любящей и уважающей поэзию и литературу в целом. Отец преподавал русскую литературу в школе, хорошо знал и татарскую, особенно любил Тукая и Такташа. Мама тоже была учительницей, из её уст лилась богатая пословицами и поговорками изящная речь. В нашем доме всегда звучали песни и стихи. Все, кроме меня, и папа

с мамой, и брат с сестрой играли на мандолине. Ещё дошкольницей я рассказывала наизусть стихи и пела песни. Я немного шепелявила, поэтому домашние, любя, посмеивались надо мной».

Безусловно, и прекрасная природа Урала с полноводными реками и озёрами, горными вершинами, таинственными пещерами, дремучими лесами, широкими полями внесла свой бесценный вклад в воспитание искренних чувств в душе поэтессы. Строя новые школы, Тавгалюну Хамматовичу приходилось часто переезжать из деревни в деревню, поэтому семья Валеевых не раз меняла место жительства. А каждый переезд — это не только новые хлопоты, но и новые интересные места, новые знакомые, новые эмоции. Резеда Валеева училась и в татарской, и в башкирской, и в русской школах, а аттестат получила в центре Салаватского района Башкортостана.

Но жизнь состоит не только из приятных событий. В эти годы на всю страну обрушилась трагедия Великой Отечественной войны. Семья Валеевых не стала исключением. Валеевым пришлось пережить боль потерь, утрат, страданий, голода, проводить родных и близких на фронт, а потом с нетерпением ждать их возвращения. Когда началась война, маленькой Резеде было всего одиннадцать лет. Для неё уход старшей сестры Раузии на фронт стал первым потрясением, большим горем. Свои переживания Резеда Валеева выразит позже в стихотворении «Косы твои», посвящённом сестре. В стихотворениях «Материнская грусть», «Помнит берёза», «Вечный огонь», «День Победы», в поэмах «Крылатый всадник», «Песнь о поэте» поэтесса передаёт тему войны, прежде всего, через сложный внутренний мир, душевную боль лирического героя, чувства и эмоции своих персонажей.

После окончания средней школы Резеда Валеева приезжает в Казань. В Казань, в которой жили и творили Такташ и Тукай. В Казань, которой грезила юная поэтесса. Она поступает в Казанский государственный университет (нынешний Казанский (Приволжский) федеральный университет) на отделение татарского языка и литературы и окунается в мир литературы и искусства. Её однокурсники — ставшие в будущем известными писателями и литературоведами Гариф Ахунов, Махмут Хусаин, Фарит Хатипов, Марат Сагитов и др. В 1952 году, окончив университет, Резеда Валеева начинает работать редактором в Татарском книжном издательстве. Её первые творческие эксперименты, первые стихи приходятся именно на эти годы. В 1960 году выходит в свет её первая книга «Мои друзья». С тех пор стихи и песни, проза и переводы, вышедшие из-под пера поэтессы, находят отголосок в сердцах тысячи читателей.

Долгие годы Резеда Валеева радует нас интересными, увлекательными, весёлыми и остроумными стихотворениями, сказками, поэмами